**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИШЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

12 октябрь 2018 ел №13

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Ишеево авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында " 2017 ел, 9 март, 4 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Ишеево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге башкарма комитеты **карар итә:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында” 2017 ел, 9 март, 4 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы "Ишеево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 16 пунктның «в» пунктчасында «мөрәҗәгать итүченең мөһере белән расланган " сүзләреннән соң «(әгәр җәмгыять уставында мөһер булу турындагы мәгълүматлар бар икән)»сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм махсус мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Ишеево авыл**
**җирлеге башлыгы** **Р.Р. Сатдинов**